**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ СТАРОКАРАМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

*423982, Р.Т. Муслюмовский район, с.Старые Карамалы, ул.Кооперативная 115а,*
Skarm.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-54-25*
ИНН 1629001113, КПП 162901001, ОГРН 1021605557907, ОКАТО 92242870000

*Иске Карамалы авылы* *« 07 » апрель 2021 ел.*

**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ Х УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 18**

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» Иске Карамалы авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү турында

Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 мартындагы 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347 номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 25 октябрь 4 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең 2 статьясына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.».

2. Әлеге карарны Иске Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru/starokaramali.htm) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Иске Карамалы авыл җирлеге Советы**
**утырышында рәислек итүче,**
**Иске Карамалы авыл җирлеге башлыгы:** **И.Н.Каримов**